ГЛАВА
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Красавина, д.40, с. Набережные Моркваши,
422594

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Красавин ур., 40 нчы йорт, Яр Буе Моркваши авылы,
422594

Тел.: (84379) 3-16-47, факс: (84379) 3-16-47.

12.04.2024 № 2

На №______________ от________________

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Урман Морквашы авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Урман Морквашы авылында гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында» 2023 елның 09 декабрендәге 3 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Урман Морквашы авылында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау) дигән мәсьәлә буенча 2024 елның 12 апрелендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 57 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 30 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 27 гражданнар җыены катнашучысы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 3 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Урман Морквашы авылында гражданнар җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Урман Морквашы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 09 декабрендәге 3 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү килешәсезме? - торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Урман Морквашы авылында җирле әһәмияттәге

юлларны ремонтлау) дигән мәсьәлә буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Урман Морквашы авылында халык җыены нәтиҗәләрен Яр буе Морквашы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: И. Х. Гаязов